**Починок-Кучук авыл җирлеге Советы**
**Кукмара муниципаль районы**

# КАРАР

**2022 елның 05 августы** **№ 17**

Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Чигайка авылында гражданнар Җыенының 16.11.2021 елдагы 1 номерлы «халыктан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча, Чигайка авылында халык җыенын билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Починок-Кучук авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 16 августында 17 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге Чигайка гражданнар җыенының, 16.11.2021 елдагы 1 номерлы «халыктан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча, үткәрүне билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегендәге Чигайка авылында узган халык җыены нәтиҗәләре турында «16.11.20021 елдагы 1 номерлы» Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә килешәсезме?:
- түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә: «- скважина бораулау, материал һәм җиһазлар сатып алу, карап тоту (проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);»

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Починок-Кучук
авыл җирлеге башлыгы: Р. Ә. Гыйниятов